Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
“Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе”
муниципаль берәмлеге Тихоновка авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы КАРАРЫ

30 ноябрь 2020 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2020 елның 29 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта, 2020 елның 29 ноябрендә 10 сәгать 30 минутта, 29 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта, 2020 елның 29 ноябрендә 13 сәгать 30 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә «Сез 2021 елда "Түбән Мактама ш. т. б. " муниципаль берәмлеге Тихоновка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (1 төркем инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдән, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толларыннан, РФ Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан тыш) 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: юлларны асфальтлау, урамнарны яктырту, энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар урнаштыру, тротуарларны ремонтлау, балалар һәм спорт мәйданчыкларын урнаштыру, һәйкәлләрне карап тоту, Малая елга яр буен төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү, күрсәтелгән эш төрләренә техник күзәтү үткәрү һәм авыл җирлеге милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 1404 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 732 кеше, бу 52,1 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 382 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 350 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тихоновка авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге Тихоновка авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2021 елда 300 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: юлларны асфальтлау, урамнарны яктырту, энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар урнаштыру, тротуарларны ремонтлау,

балалар һәм спорт мәйданчыкларын урнаштыру, һәйкәлләрне карап тоту, Малая елга яр буен төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү, күрсәтелгән эш төрләренә техник күзәтү үткәрү һәм авыл җирлеге милкенә рәсмиләштерү өчен түләү.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетысында бастырырга, Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Р.А. Бәдретдинов